**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 24 август № 618

г. Казань

«Зөя утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музее» Татарстан Республикасының дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе исемен үзгәртү турында

Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасын киләчәктә саклау һәм популярлаштыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Зөя утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музее» Татарстан Республикасының дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе исемен «Зөя утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасының дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә үзгәртү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына ике ай эчендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Зөя утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музее» Татарстан Республикасының дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе уставына үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\618.docx